Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№24 (117)

11 сентябрь 2014 ел



Таныш булыгыз, сәхифәбезнең бүгенге герое – Динара Хәбибуллина. Үзбәкстанда туып үскән татар кызы ул. Бүген КФУның Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтының 2 курсында белем ала. Аралашучан, позитив, кешеләрне һәм тормышны яратучы Динара – булачак татар теле, әдәбияты, инглиз теле укытучысы.

# «345 көн буе өемә кайтмадым!»

## Вакыйгалар эзеннән

**КФУның 53 СТУДЕНТЫ ТР ПРЕЗИДЕНТЫ СТИПЕНДИЯСЕН АЛАЧАК**. Алар арасында Россия һәм халыкара олимпиадалар, иҗади конкурс, фестиваль җиңүчеләре; төрле ачышлар, Россия һәм аннан читтә чыга торган үзәк басмаларда дөнья күргән фәнни мәкалә авторлары бар. Стипендия агымдагы елның 1 сентябреннән биреләчәк. Югары уку йортлары аспирантлары, адъюнктлары өчен ул 3330, ә студентлар һәм курсантлар өчен 2780 сумны тәшкил итә.

• • • •

**8 СЕНТЯБРЬДӘ** КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** Санкт-Петербург Халыкара менеджмент институты ректоры **С.МОРДОВИН** белән **ОЧРАШТЫ**. КФУга килгән кунак өчен Актлар залы, Ленин аудиториясе һәм Э.А.Эверсман ис. зоология музеена экскурсия оештырылды. Шулай ук җитәкчеләр югары уку йортлары арасында мөмкин булган уртак белем бирү программалары хакында да сүз йөртте. С.Мордовинның КФУга визиты кысаларында MBA программасы тыңлаучылары өчен лекцияләр оештырылды.

• • • •

Шул ук көнне КФУда Аичи университеты профессоры **ТАКАХАСИ МИЮКИ** япон мәдәнияте турында **ЛЕКЦИЯ УКЫДЫ**. Ул тыңлаучыларны борынгы япон гореф-гадәтләре белән якыннанрак таныштырды. Лектор белдерүенчә, мондый лекцияләр төрле милләтләр арасында мәдәни алмашу шартларын тудыру, халыкара мөнәсәбәтләрне киңәйтү өчен кирәк. Такахаси Миюки катнашучыларны оригами сәнгате серләренә дә төшендерде – аларга кәгазь торналар ясарга өйрәтте.

• • • •

9 сентябрь көнне ТРның Яшьләр оешмасы советы Татарстанның яшьләр сәясәтенә 20 булу уңаеннан **«ЯШЬЛӘР ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАЛАРЫ: КИЧӘ, БҮГЕН, ИРТӘГӘ»** исемле түгәрәк өстәл уздырды. Чараның төп максаты – дәүләт яшьләр сәясәтенең күпьеллык эш тәҗрибәсе нәтиҗәләре, тенденцияләре һәм үсеш перспективалары белән танышу. Түгәрәк өстәл утырышына республикабызның депутатлары да чакырулы иде.

• • • •

Шул ук көнне **КФУ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕ** Вагенинген университеты (Голландия) профессоры **ВИМ ХАЙМАН** белән **ОЧРАШТЫ**. Вим Хайман төбәк икътисады профессоры һәм «Abstract» журналының мөхәррире буларак билгеле. Галим белән очрашуда югары уку йортлары арасындагы хезмәттәшлекне үстерү турындагы тәләк-тәкъдимнәр яңгырады. Ректор И.Гафуров Россиянең икътисад өлкәсендә югары квалификацияле белгечләргә ихтыяҗы аеруча зур булуы хакында җиткерде. Ул Вим Хайманга КФУга Вагенинген университеты галимнәрен чакыру, дистанцион курслар оештыру тәкъдиме белән мөрәҗәгать итте.

• • • •

КФУның Яр Чаллы институты һәм «КАМАЗ» ААҖ арасындагы хезмәттәшлек кысаларында студентлар «КАМАЗ» оешмасының куркынычсызлык буенча генераль директоры урынбасары **И.ШАМИЛОВ** белән **ОЧРАШТЫ**. Кунак карьерада уңышка ирешү серләре белән уртаклашты. Очрашу ахырында һәр катнашучыга «Тормыш максатларын кую методикасы» тестын өләштеләр.

• • • •

**9 СЕНТЯБРЬ** көнне Казан университеты Тарихы музеенда **«БИЛГЕЛЕ СОЛДАТ КАБЕРЕ»** дип исемләнгән **ФИЛЬМ КҮРСӘТТЕЛӘР**. Кайчандыр КФУ студенты булган, хәзер ВВС телеканалында эшләүче Ольга Ившинаның әлеге документаль картинасы Бөек Ватан сугышында үлеп калган сугышчыларның калдыкларын эзләү, аларны күмү белән шөгыльләнүче кешеләр эшчәнлегенә багышланган. Мондый эзләү отрядлары илебездә 1998 елда оеша башлады. Фильм авторы фикеренчә, мондый авыр һәм кирәкле хезмәт башкарган кешеләрне якыннары гына түгел, бөтен дөнья белергә тиеш.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

## Сайлау-2014

# Ә син сайлауга барасыңмы?

**Күптән түгел КФУның «Уникс» спорт комплексы каршындагы мәйданда «Мин сайлауга барам!» акция-флэшмобы узды. Студентларга юнәлтелгән әлеге чараның төп максаты – яшьләргә 14 сентябрь көнне узачак сайлаулар турында тулырак мәгълүмат бирү һәм аларның гражданлык активлыгын үстерү.**

**Ләйсән ИСХАКОВА**

«Кадровый резерв» республика проекты, «Татарстан иҗади яшьләр академиясе» оешмасы әлеге акцияне республиканың Үзәк сайлау комиссиясе белән берлектә оештырган. Чара кысаларында ике интерактив мәйданчык әзерләнгән иде. Аның берсендә катнашучыларга сайлау билгесе сурәтләнгән наклейкалар өләштеләр. Һәр теләгән кеше бу тамганы Татарстан картасы төшерелгән баннерга, үзе туган яки яшәгән төбәк урынына ябыштырып куя алды. Акциядә катнашучылар әлеге баннер янында фотога төшеп, сурәтне социаль челтәрләрдә урнаштыру мөмкинлегенә дә ия булды.




«Флэшмоб «Безнең республика: горурланабыз һәм яратабыз» марафоны кысаларында уза. Бу чара ярдәмендә без яшьләрдә сайлауларга карата уңай кичерешләр уятырга һәм аларның игътибарын бу мөһим вакыйгага юнәлтергә телибез», – дип белдерде «Кадровый резерв» проекты җитәкчесе **Валентин Шихобалов**.

Икенче мәйданчыктагы баннерда исә сайлау тартмасы төшерелгән иде. Һәрбер катнашучы әлеге баннер фонында сайлау белән бәйле кызыклы һәм шаян язулы креатив табличкалар тотып фотога төште. Оештыручылар барлык фотосурәтләрне **#яидунавыборы** хэштегы белән популяр социаль челтәрләрдәге төркемгә «эләргә» сүз бирде. Студентлар әлеге акциядә бик теләп катнашты. Алар модераторлардан булачак сайлаулар турында сорашты, баннерлар фонында истәлеккә фотога төште.

«Мин быелгы сайлауга барырга җыенам. Үз гомеремдә беренче тапкыр. Бу акция ярдәмендә сайлауларның шактый катлаулы, әмма кирәкле процесс икәнлегенә төшендем», – дип фикерләре белән уртаклашты КФУның 2 курс студенты **Алия Гыймадова**.

Һәр катнашучыга яидунавыборы хэштегы белән сайлау датасы күрсәтелгән наклейкалар, республика флагы рәвешендәге тасмалар, магнитлар, мәгълүмати буклетлар һәм сувенирлар таратылды. Ә иң кечкенәләр өчен төрле төстәге шарлар әзерләнгән иде.

«Сайлаулар – илебез, республикабыз тормышындагы мөһим вакыйга. Студентлар да, үзләренең сайлау хокукыннан файдаланып, тавышларын бирсеннәр иде. Чөнки һәр тавыш игътибарга лаек. Һәрберебез республикабызны яхшырту, үстерүгә үз өлешен кертә ала!» – диде «Татарстан Балалар оешмалары советы»ның идарәче ярдәмчесе **Юлия Ширчикова**.

Оештыручылар хәбәр итүенчә, «Мин сайлауга барам!» акциясе моның белән генә тәмамланмады. Чара 7 һәм 9 сентябрьдә Казанда узды, 12 сентябрь көнне исә Чаллыда оештырылачак. Барлык тавыш бирүчеләр 14 сентябрьдә «Казан Арена»да узачак бәйрәм концертында күңел ача алачак. Әлеге тамаша иртәнге 10да башланып, төнгә кадәр дәвам итәчәк.

## Изге гамәл

# «Эзләп тапкан матурлык»

**КФУ студентлары кайда гына бармыйлар, ниләр генә эшләмиләр! Бәлки, КФУ студентларының үзенчәлеге дә шулдыр? Алар уку белән ялны, файдалы, савaплы эш белән мәгълүмат туплауны бергә алып бара ала.**

Бу юлы университетыбыз студентлары Эльбруска кадәр менеп җитеп, анда сугыш вакытында илебез өчен кан койган, батырларча һәлак булган солдатларга истәлек такталары урнаштырды.

Экспедициянең оештыручысы һәм җитәкчесе – КФУның Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институтының 2 курс студенты Влас Максимов. Аның белән бергә КФУ студенты Фаяз Хайруллин, менеджер Виталий Сыроватский һәм элеккеге камазлы Владимир Пальников диңгез өстеннән 5200 метр биеклеккә күтәрелде. «Без анда бары кыялар, бозлар, ташлар һәм салкын елгалар гына булачагын аңлый идек. Интернет, телефон, такси һәм GPRSлар турында, гомумән, онытык. Агачлар кайда үсәсе килсә, шунда үсә, ташлар үзләренә ошаган җирдә ята, елга кайсы якка агасы килсә, шулай ага. Шундый шартларда кешенең бары кеше генә булуына төшенәсең», – дип искә ала В.Максимов.

Альпинистларның сәяхәте Югары Баскан поселогы – ВЦСПС перевалы – Койавганаүш перевалы – Терскол перевалы буйлап 13 көн буе дәвам иткән. Сәяхәт кылучыларга «Сугышчы даны» перевалы бик гаҗәеп кебек тоелган: «Бик арыган идек, әмма барыбер алга барыбызны дәвам иттек. Ярылган боз аркылы сикереп чыкканнан соң, күкерт исе килә башлады. Вова абый сүзләренчә, вулканнан нәкъ менә шундый ис килә икән. Чыннан да, тирә-ягыбызда вулкан токымы иде. Әмма игътибарымны тагын бер әйбер җәлеп итте: бозга каткан табышымны каерып алганнан соң, аның мина кыйпылчыгы икәнен аңладым», – дип уртаклашты җитәкче хатирәләре белән.




«Сугыш кайтавызы» перевалында бүгенге көнгә кадәр блиндажлар, немецларның консерва банкалары, гильзалары, кыйпылчыклар, снаряд тартмалары сакланган. Алар барысы да бозга катып калганнар.

Бу тауда истәлек такталарының саны бик күп икән. Аның иң беренчесе 69 ел элек, сугыш беткәч үк куелган. Вафат булган совет альпинистларына рәхмәт сүзләре соңгы тапкыр 1990 елда беркетелгән.

Планлаштырганча, КФУлылар Бөек Ватан сугышы вакытында һәлак булган совет сугышчы-альпинистлар истәлегенә 3 мемориаль такта куйган. Аларда «Кавказны яклаучыларга мәңгелек истәлек. Яр Чаллы шәһәре яшьләреннән» дип язылган. Альпинистлар, үз эшләре белән горурланып: «Бу гамәлебез Бөек җиңүнең 70 еллыгына эшли алганның кечкенә бер өлеше генә», – ди. Алай гына да түгел, алар икенче елга да бирегә килергә исәпли: «Кайчакта авыр рюкзаклар белән югарыга үрмәләгән вакытта «кирәк идеме бу миңа?» – дип уйлап куясың. Өйдә ял итеп яткан булсам... Әмма тауның очына менеп җиткәч, андагы гүзәллеккә таң каласың һәм аңлыйсың: монда кадәр менеп җитү – бик зур батырлык. Андагы матурлыкны болай гына күреп булмый, аны хезмәт куеп күрергә кирәк!»



*Материал Матбугат үзәге мәгълүматлары ярдәмендә әзерләнде*

● Сәяхәт

Материалларның авторы **Ләйсән ИСХАКОВА**

Сәяхәт – кешене гомере дәвамында озатып йөриячәк алыштыргысыз тәҗрибә һәм белем ул. Бөек Лао-Цзы: «Мең чакрымлык юл бер адымнан башлана», – дип әйтеп калдырган. Шәхес үсеше өчен дә нәкъ менә шул адым кирәк. Шулай да, сәфәргә чыкканчы, чит илләр-җирләр турында билгеле бер күзаллау тудыру кирәк. Бу максаттан, без бүген Сезне Иран дигән серле ил белән якыннанрак танышырга чакырабыз.



# Иран – серле дә, гаҗәеп тә

### *Тарихка күз салсак...*

Иран Ислам Республикасы – безнең өчен шактый серле, таныш түгел, әмма, шуның белән беррәттән, үзенә чакырып, дәшеп торучы ил. Без аның турында нәрсә беләбез соң? Биредә дөньядагы нефть запасының 60 % саклана, җирле халыкның якынча 70 % әле 30 яшькә җитмәгән. Кемдер иранлыларны гарәпләр, дип уйлый. Чынлыкта исә алар – фарсылар. Иранлылар үзләренең Бөек Фарсы империясе варислары булулары белән горурланып яши. Иран без, татарлар өчен, бөтенләй үк чит-ят дәүләт түгел. Тарихчылар исәпләвенчә, борынгы бабаларыбыз – төркиләр – Иран белән мөнәсәбәтләрне VI гасыр башында ук урнаштыра. Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителгәннән соң исә, мөнәсәбәтләр тагын да ныгый төшә. Борынгы галимнәребез Иранның төрле шәһәрләренә барып, белем эстәп кайта торган булганнар. XI йөздә яшәгән Иран тарихчысы Әбел-Фазыл Бәйһакый 1025 елда Болгар хөкемдары Әбу Исхак Ибраһим бине Мөхәммәднең Нишапур өлкәсенә ике мәчет төзетерлек акча җибәрүе турында язып калдырган. Төркиләрнең уртак әдәби мирасы булып саналган Алтын Урда чорында иҗат ителгән әсәрләрнең күбесе фарсы әдәбияты үрнәгендә язылган. Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки»е, Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се нәкъ менә шулар рәтендә. Күтәрелеш чоры саналган XX йөз башында да татарларда Шәрык, шул исәптән Иран белән кызыксыну арта. Борынгы бабаларыбызның фарсылар белән аралашып яшәве телебездә дә чагылыш таба. Чөнки татар теле составында фарсы теленнән кергән сүзләр шактый.

### *Татлы әфлисуннар иле*

Тагын кайсы без белмәгән үзенчәлекләре белән дан тота соң иранлылар? Баксаң, алар ике мең ярым ел дәвамында дөньядагы иң шәп келәм тукучылар булып танылган. Биредәге халык ил буйлап кечкенә автобусларда хәрәкәт итә; гаиләләре белән кичке намазга йөри; Фирдәүси, Сәйяди, Хайям, Хафизи кебек бөек шагыйрьләренең әсәрләрен укырга, тыңларга һәм сөйләргә ярата. Биредә иң татлы әфлисуннар, тәмле йөзем һәм искиткеч зур анар җимешләре үсә.



### *Гөлстан – чәчәкләр бакчасы*

Иран башка илләрдән борынгы шәһәрләргә бай булуы белән аерылып тора. Шундыйларның берсе – Тәһран, ягъни Тегеран. Ул Иранның башкаласы һәм иң зур шәһәре булып санала. Шәһәр – илнең сәяси, икътисади, мәдәни, транспорт һәм сәүдә үзәге. Тәһранның төньяк өлешендә күпкатлы торак йортлар, бассейны, теннис кортлары булган искиткеч зур, купшы виллалар урнашкан. Биредә берничә шаһ сарае да бар. 1979 елдан алар милли музей, күпсанлы уку йортлары, кыйммәтле кибетләр, кунакханәләргә әйләндерелгән. Шулай да Тәһранның иң борынгы районнары – көньякта. Биредәге иң төп истәлекле урын – Зур Базар. Иранлылар үзләре әлеге Базарда җаның ни тели, шуны сатып алып була, дип сөйли. Ә инде таба алмагансың икән, мондый әйбер Җиһанда да юк, дип шаярта алар. Иранның тагын бер борынгы һәм үзенчәлекле шәһәре – Исфаханә. Биредә шаһитлар зираты – Гөлстан бар. Әлеге зиратта, ил азатлыгы өчен үзләрен корбан итеп, шаһит китүчеләр күмелгән. Монда идеаль чисталык өстенлек итә. Зират каралган, аллы-гөлле чәчәкләргә күмелгән. Бу аңлашыла да, чөнки Гөлстан батырларның чәчәк бакчасы, дип тәрҗемә ителә.

Иран искиткеч матур сарайлары, мәчетләре, нәкыш бизәкле көмеш савыт-сабасы, тәм-томнары, көнчыгыш базарларының сирәк очрый торган һәм кабатланмас мөхите белән дан тота. Базар – сату-алу гына түгел, ә ял итү, аралашу-дуслашу урыны да. Андагы мөхит илне һәм аның кешеләрен танып белергә, аңларга ярдәм итә. Нәкъ менә биредә читтән килгәннәрне кочак җәеп, елмаеп каршы алалар, чөнки Иран – яхшы һәм дустанә кешеләр иле.

● Алар бездә укыган

Бүген сабыйларга акыл, белем һәм тәрбия бирүгә ярдәм итә торган чара-мөмкинлекләр күптәрле. Кибеттә балалар өчен кызыклы китапларны, игътибар, сабырлык, зирәклекне үстерүгә юнәлтелгән уеннарны бер авырлыксыз табарга мөмкин. Кызганыч, ләкин аларның күпчелеге рус телендә. Нәкъ менә шуны истә тотып, Тюльпан Миңнаҗева «Акыллым» проектына алынырга була да инде. Кайчандыр КФУның Идарә, икътисад һәм финанслар институтын тәмамлаган кыз бүген үзендә яңа сәләтләр ача.

# «Акыллым» татарчага өйрәтә

«Акыллым» – татар телен бишектән өйрәнү системасы. Ул үзенчәлекле иллюстрацияле карточкалар җыелмасыннан гыйбарәт. Система күренекле америка врач-физиотерапевты, галим Глен Доман методикасына нигезләнгән. Доман сабыйларның күреп истә калдыру сәләтенә зур игътибар бирә. Шуңа бәйле рәвештә, аның методикасында рәсем һәм кызыл төстәге эре хәрефле сүзләр төшерелгән карточкалар кулланыла. Доман фикеренчә, сабый өчен аерым хәрефләргә караганда тулы бер сүзне аңлау, истә калдыру күпкә җиңелрәк. Ә менә Тюльпан шундый карточкаларның татар телендәгеләрен әзерли.







Ире Булат, уллары Арслан тугач, Доман карточкаларының русча вариантын алып кайта. Бала белән шөгыльләнә башлагач, аның рәсем атамаларын рус телендә истә калдыру куркынычын аңлап, Булат һәм Тюльпан мондый карточкаларның татарчасын эзләп карый. Әмма аларның юклыгы ачыклана. Шуңа Тюльпан Доман карточкаларының татар вариантын эшләп карарга була. Бүген исә «Акыллым» проекты кысаларында 3 үзенчәлекле иллюстрацияле карточкалар җыелмасы бастырылган инде. Төп җыелма 6 теманы үз эченә алган А5 форматындагы 120 карточкадан тора. Алардагы сүзләр һәм рәсемнәрнең һәркайсын Тюльпан үзе сайлаган, эшкәрткән һәм әзерләгән. Рәсемнәр ак фонда урнаштырылган, бу исә предмет яки күренешне кабул итүне тагын да җиңеләйтә. Кире яктагы сүзләр исә эре кызыл хәрефләр белән язылган. Алар баланың хәтерен, игътибарын чыныктыра, күреп истә калдыру һәм тумыштан дөрес яза белү сәләтен үстерә. «Бер яшьлек улым Арсланга әлеге карточкалар бик ошый. Ул бигрәк тә рәсемнәрне карарга ярата. Карточкалар сыйфатлы кәгазьдән эшләнгәнгә, бала ертыр, дип борчыласы юк. Кырыйлары очлы түгел, түгәрәкләнгән. Бу сабый киселә, җәрәхәтләнә күрмәсен өчен махсус эшләнгән», – дип аңлатты Тюльпан. Проект авторы әйтүенчә, өйрәнүне нәкъ менә төп җыелмадан башларга кирәк. Ул балага әйләнә-тирә, әйбер-күренешләр, кешеләр һәм җанварлар турында күзаллау тудырырга ярдәм итә. Сүзләрне сайлау, сыйфатлы рәсем табу, аны фотошопта эшкәртү, карточкаларны бастыру беренче карашка җиңел тоелса да, чынлыкта авыррак булып чыккан.

«Үзебезгә эшләгән беренче чыгарылышта хаталар да шактый иде. Аннан ирем Булат белән уйладык та, сабыйларын татарча тәрбияләргә теләүче әти-әниләргә ярдәмлек рәвешендә чыгарылышларны төрләндереп таратырга булдык», – ди Тюльпан.

Шул рәвешле төп җыелмага өстәмә чыгарылышлар да әзерлиләр. Алары инде баланың белемен, тел байлыгын, күзаллавын тагын да тирәнәйтү, баетуга юнәлтелгән. Мисал өчен, «Ел фасыллары» җыелмасында 60 карточка. Аларда гаҗәеп матур табигать күренешләре төшерелгән һәм аларның атамалары язылган. Әлеге җыелма ярдәмендә әти-әниләр сабыйларын ел фасылларын аерырга өйрәтә, аларга җиләк-җимеш, яшелчәнең кайчан чәчәк атуын, өлгерүен, кышкы, язгы, җәйге һәм көзге урманның нинди булуын аңлата ала.

«Акыллым» проектының өченче җыелмасы – «Укырга өйрәнәбез» дип атала. Ул алфавитның һәр хәрефенә багышланган 38 сүзне үз эченә алган. Әлеге җыелманы Тюльпан әнисе, Татарстанның атказанган укытучысы, 36 ел гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган Гөлфия Хәбибуллина ярдәмендә эшләгән. Чөнки балаларны укырга өйрәтүнең үз нечкәлекләре, үзенчәлекләре бар. Биредә авторлар сүзләрнең сирәк очрый торганнарын, кулланылыштан төшеп калганнарын сайлап алырга тырышкан. Чөнки, беренчедән, бу баланың тел байлыгын арттырырга, икенчедән, дәресләрне төрләндерергә ярдәм итә. Карточкаларның кире ягында һәр хәрефкә иҗекләп шигырь яки табышмак язылган. Аларның һәммәсен авторлар үзләре иҗат иткән. Бу эштә Тюльпанга иптәш кызы Гөлназ Гыйләҗева да булышкан. Әлеге җыелмадагы сүзләр арасында мин рәйхан (базилик), һөдһөд (удот), зелпе (жимолость), шәфталу (персик) кебек көндәлек аралашуда сирәк кулланыла торган сүзләрне очраттым. Җыелмаларны сатып алучылар, сораучылар, проект белән кызыксынучылар күп икән. Татарстанда гына түгел. «Акыллым»ның бер җыелмасы Иваново шәһәренә «киткән». Тагын бер җыелманы почта аша җибәргәннәрен инде Финляндиядә көтеп торалар. Димәк, сабыйларын бишектән татарчага өйрәтергә, аларга милли тәрбия бирергә теләүче гаиләләр бар. Ихтыяҗ булгач, Тюльпан тормыш иптәше белән бергәләп бу проект өстендә эшләвен бүген дә дәвам итә. Бүгенге шартларда балага туган телне өйрәтү – көнүзәк мәсьәлә. Бу уңайдан Тюльпан үз фикерләрен җиткерде: «Татар телен сабыйга кечкенәдән сеңдерергә кирәк. Әлбәттә, моның өчен иң мөһиме – гаиләнең туган телдә аралашуы. Ә татарча карточкалар, китаплар ул бары тик өстәмә ярдәмче генә. Миңа калса, һәр татар баласы, үзенең фикерен җиткерә алырлык дәрәҗәдә генә булса да, туган телен белергә тиеш. Киләчәктә кулланырмы ул аны, юкмы – анысын үзе хәл итәр. Ә менә сөйләшәсе килеп тә, татарча сөйләшә алмаса, аңа кыен булачак».

● Таныш бул!

# «345 көн буе өемә кайтмадым!»

Чит илдән килеп, туган телендә белем алырга, үз халкының милли, мәдәни, рухи, тарихи үзенчәлекләрен өйрәнергә омтылган бу чая кыз белән якыннанрак аралаштык.

**– Динара, син Ташкентта туып үскән кыз. Ничек итеп татарча шулай камил сөйләшәсең?**

- Мин кечкенәдән әбибабай белән үстем. Бабам чыгышы белән Казан артыннан, Арча районы Иске Кишет авылыннан. Әбием белән бабам мине кечкенәдән «Син татар телен белергә, өйрәнергә тиеш», – дип үстерде. Мин үзем дә «Чит телне белү кирәк, туган телне белү тиеш», дигән мәкальгә таянып яшим.

**- Үзбәкстан мәктәп программаларында татар теле дәресләре, гомумән, юк бит?**

- Чыннан да, бу шулай. Чөнки бездә үзбәк һәм рус телләре дәүләт телләре булып санала. Мин татар телен укып, сөйләшеп, аралашып өйрәнгән кеше буларак, монда килгәч, татар әдәби телендә дөрес язу белән бераз авырлыклар туды. Хәзер инде, Аллага шөкер, өйрәнеп барам.

**- Ни өчен нәкъ менә татар филологиясе һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлеген сайладың?**

- Мин һәрвакыт КФУның татар филологиясе бүлегендә укырга омтылдым һәм моңа ирешүемә бик шатмын. Киләчәктә дә үзем укыган белгечлек буенча эшлисем килә. Тел, әдәбият юнәлеше минем өчен бик кызыклы.

**- Ә шулай да, татар һәм инглиз теле арасыннан кайсысын аеруча теләп өйрәнәсең?**

- Минем өчен татар теле, әдәбияты фәннәрен үзләштерү инглиз теленә караганда бераз авыррак бирелсә дә, туган телемне, әдәбиятымны өйрәнү миңа бик ошый. Әсәрне уку барышында татар телендәге яңа сүзләргә юлыксам, аларның тәрҗемәсен табып, язып куярга, отып алырга тырышам. Буш вакытларымда татар язучыларының әсәрләрен укыйм. Әлбәттә, укырга кирәк булган өчен генә түгел. Бу шөгыль миңа чын-чынлап ләззәт китерә. Миңа Тукай иҗаты якын. Әдәбият дәресләрендә дә бик күп татар язучыларының әсәрләре белән таныштык. Университетыбызда безгә югары квалификацияле, үз фәнен дөрес итеп аңлата торган белгечләр белем бирә. Бу яктан без бәхетле.

**- Укудан тыш нинди шөгыльләрең бар?**

- Мин биергә яратам. «Яшьлек» бию коллективына йөрим. Сәхнәгә чыгу көнелдә уңай кичерешләр уята. Күбрәк халык биюләрен өйрәнәбез. Узган ел бик теләп КФУның «Студентлар язы»нда катнаштык.

**- Син әле модель дә бугай?**

- Әйе, 13 яшемнән Ташкенттагы Asian Style модель агентлыгына йөрдем. Әмма тормышымны бу юнәлешкә багышлыйсым килмәде. Хыялым Казанга укырга керү иде. Менә бүген, максатыма ирешкәч, модель булу хоббием булып кала бирә. Казанда исә «Ильданлик» мода театрына йөреп алдым. Һөнәри фотографларның эшчәнлеге, дизайнерларның коллекцияләре белән танышып бару миңа бик кызыклы. Шул рәвешле үземне мәдәни яктан камилләштерәсем килә.



**- Модель буларак нинди чараларда катнаштың?**

- Быел Казанда узган «Islamic Clothes-Fashion» халыкара мөселман киеме фестивалендә тамашачыларга дизайнер Айсылу Кәлимуллина коллекциясен тәкъдим иттек. Айсылу әлеге фестивальдә жиңеп чыкты. Шулай ук май уртасында үткәрелгән Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумында да татар милли мөселман киемнәре коллекциясен күрсәттек. Мондый чараларда катнашу көндәлек тормышка ямь өсти, кәефне күтәрә.

**- Динара, җәйге елларың ничек узды?**

- Туган шәһәрем Ташкентка елга 1 мәртәбә, җәйге каникулларга гына кайтам. Әлбәттә, туган ягым бик сагындыра. Хәтта көннәрне дә санадым – өемә кайтмаганыма нәкъ 345 көн булган иде. Менә, ниһаять, җәйге елларда өйдә торып килдем. О, еллар бик шәп узды! Җәй бездә бик эссе – һава температурасы хәтта 50 градусларга кадәр җиткән чаклар да булгалады. Якыннарым, туганнарым белән табигать кочагында ял иттек, паркларга бардык. Җәйге мизгелләрне фотосурәт һәм видеолардан карап искә алырга гына калды... Әмма моңсуланып утырырга вакыт та, теләк тә юк!

**- Укуны тәмамлагач, Казанда калырга уйлыйсыңмы?**

- Әйе, мөмкинлек булса, биредә калырга исәп бар. Казан миңа бик ошый. Ул минем туган шәһәремә әверелеп бара. Миңа калса, Казан – хыялларны тормышка ашыру өчен менә дигән шәһәр!

**- Яңа уку елына нинди өметләр баглыйсың?**

- Семестр ахырында биреләчәк имтиханнар исемлеге билгеле булды. Татар теле, әдәбиятыннан сынаулар көтелә. Бу – шәхсән минем өчен авыр имтиханнар. Шуңа бар көчемне укуга юнәлтергә уйлыйм. Авырлыклар, сынаулар аша ирешелгән уңышлар, уңай нәтиҗәләр икеләтә кадерле була. Шулай ук уку йортыбыз, институтыбыз, тулай торагыбыз тормышында да актив катнашырга ниятлим. Миңа калса, теләк булганда, барлык максатларга да ирешеп була.

● Дөнья үзебезнеке



## Бәхет чыганагы

– Мин сезгә белем бирдем, әмма бәхетне һәрберегез үзегез эзләп табарга тиеш, — диде укытучы мәктәпне яңа гына тәмамлаучы укучыларына.

– Укытучым, бәхет һәрвакытта да тиз бетә, – дип кемдер аның сүзләренә каршы төште.

– Дөньяда бетми торган бер бәхет чыганагы бар. Аны бер тапкан кеше, гомере буе бәхетле булачак, – дип җавап кайтарды укытучы.

Укучылар саубуллаша һәм укытучыларына бәхетне ничек эзләгәннәрен сөйләр өчен, өч елдан соң яңадан җыелырга сүз куеша.

Вакыт бик тиз үтеп китә. Беренче укучы килми, ул укытучысына бары хат кына җибәрә.

– Мин бәхет чыганагын таптым. Ул – хакимлек итү. Мин хакимлек баскычыннан ышанычлы рәвештә өскә таба менәм һәм аның иң югары баскычына җитәргә телим.

Икенче укучы укытучысына «Бәхет – ул байлык» дигән язу җибәрә.

Өченче укучыдан хәбәр булмый. Кемдер укытучыга аның көчле сугышчы булуын һәм армия белән башка илләрне яуларга китүен әйтә. «Күрәсең, минем укучым бәхетне көче ярдәмендә тапмакчы булган», – дип, сагышланып уйлап куя укытучы.

Дүртенче укучы гына укытучысы янына килеп, үзенең дәвалаучы булуын әйтә:

– Мин төрле җирләрдә булдым, кешеләрне савыктырдым. Алар шатланалар һәм, шуның нәтиҗәсендә, бәхетлерәк булалар. Кешеләргә бәхет китерсәң, ул һәрвакытта да синең белән булачак, – дип укучы үз сүзләрен дәлилли.

– Син иң мөһимен аңлагансың, укучым, – ди мөгаллим шатлыгын яшерә алмыйча. – Бәхетнең саекмас чыганагы – ул яхшылык эшләү омтылышы. Кеше әлеге чыганакка ешрак мөрәҗәгать иткән саен бәхетлекрәк була!

● Киңәш-табыш

# Гөмбә – җыя белсәң генә «ит»...

Көз яңа уку елы башлану чоры гына түгел, гөмбә сезоны да. Сезнең арагызда да гөмбә сөючеләр аз түгелдер. Шуңа күрә, дустым, сиңа бер-ике киңәшебез бар!

Гөмбәдә азотлы матдәләр, бигрәк тә азот күп. Ул кешеләр өчен кирәкле РР, Д витаминнарына бай. Гөмбә җыю өчен тәҗрибә, осталык, аларны яхшылап танып белү кирәк.

Гөмбә ашап агуланмас өчен, түбәндәге кагыйдәләрне үтәргә кирәк:

- Гөмбәнең үзең белгән төрен генә җыярга.
- Гөмбә шикләндерсә, ташларга – ашап карарга ярамый.
- Гөмбәне эшләпәсеннән түгел, сабыннан өзәргә (агулы гөмбәне сабы аша белергә була).
- Гөмбәнең эшләпәсен кырып чистартырга, өстендәге элпәсен кубарып алырга киңәш ителә, чөнки зарарлы матдәләр, агулар шушы элпәдә күп була.
- Артык зур, бозылган, черек, кортлы гөмбәләрне җыймагыз.
- Гөмбәләрне җыйган көнне үк эшкәртергә кирәк.

Аз гына агулану билгеләре сизү белән, табиб чакыртырга кирәк. Иң беренче итеп, эчтән агулы матдәләрне чыгарырга кирәк. Моның өчен сода яки марганцовка эретелгән 1,5-2 литрлар чамасы су эчеп косарга кирәк. Соңыннан активлаштырылган күмер эчәргә киңәш ителә, аз гына тоз өстәлгән салкынча су, салкын кофе, сөт, чәй эчәргә мөмкин. Спиртлы эчемлекләр эчәргә рөхсәт ителми, алар гөмбә агуының тизрәк сеңүенә китерә.



Табиб килгәнче, корсак, аяк өлешенә җылыткыч куярга.

Күңелсез хәлләргә юлыкмас өчен сак булыгыз!

● Игътибар! Белдерү!

Сезнең акча эшлисегез киләме? Ләкин укуны да калдырырга ярамый! Алайса, рәхим ит! Атнага өч мәртәбә Казан федераль университеты биналары буенча газета тарату өчен КУРЬЕР кирәк. Уку белән эшне бергә алып барырга риза булган егет кешеләр редакциягә мөрәҗәгать итә ала: Пр.Нужин ур., 1/37, 318 кабинет. Телефон: 233-70-04.

DARELFӨNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.